КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 31 май г.Казань № 425

Җирле үзидарә органнары тарафыннан гражданнарны авария хәлендәге торак фондыннан күчерү буенча вәкаләтләрне башкарганда барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Җирле үзидарә органнары тарафыннан гражданнарны авария хәлендәге торак фондыннан күчерү буенча вәкаләтләрне башкарганда барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен расларга.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2021 ел, 31 май, 425 нче карары белән расланды

Җирле үзидарә органнары тарафыннан гражданнарны авария хәлендәге торак фондыннан күчерү буенча вәкаләтләрен башкарганда барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибе

1. Бу Тәртип Җирле үзидарә органнары тарафыннан гражданнарны авария хәлендәге торак фондыннан күчерү буенча вәкаләтләрен башкарганда барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре (алга таба – муниципаль берәмлекләр) бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр (алга таба – субсидияләр) бирү механизмын билгели.

2. Субсидияләр гражданнарны авария хәлендәге торак фондыннан күчергәндә барлыкка килә, түбәндәгеләрне күздә тота торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында муниципаль берәмлекләр бюджетларына бирелә:

күпфатирлы йортларда (шул исәптән төзелеше тәмамланмаган күпфатирлы йортларда), шул исәптән алга таба социаль наем шартнамәсе, яки социаль файдаланудагы торак фондының торак урынын наемга алу шартнамәсе, яки авария хәлендәге торак фондыннан күчерүгә бәйле рәвештә маневрлы фондның торак урынын наемга алу шартнамәсе буенча, яки авария хәлендәге торак фондының торак урын милекчесе белән алышу шартнамәсе буенча гражданнарга торак урыннар бирү максатларында торак урыннар сатып алу һәм мондый йортларны төзү;

үз милкендә авария хәлендәге торак фондына керә торган торак урыннары булган гражданнарга Россия Федерациясе Торак кодексының 32 статьясындагы 7 өлеше нигезендә нигезендә алына торган торак урыннар өчен акча түләү.

3. Бу Тәртип нигезендә бирелә торган бюджет акчасы белән баш эш итүче булып Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы (алга таба – Министрлык) тора.

4. Субсидияләр Татарстан Республикасы бюджетыннан, шул исәптән Торак-коммуналь хуҗалыкны реформалауга булышлык күрсәтү фонды – дәүләт корпорациясеннән кергән акча исәбеннән бу Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән максатлар өчен тиешле финанс елына бюджет акчасын алучы буларак Министрлыкка җиткерелгән бюджет ассигнованиеләре лимитлары чикләрендә бирелә.

5. Субсидияләр бирү өчен муниципаль берәмлекләрне сайлап алу критерийлары – 2017 елның 1 гыйнварына кадәр авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле дип билгеләнгән тәртиптә танылган һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019 – 2025 елларга авария хәлендәге торак фондыннан гражданнарны күчерү буенча республика адреслы программасын раслау турында»

2019 ел, 29 март, 242 нче карары белән расланган 2019 – 2025 елларга авария хәлендәге торак фондыннан гражданнарны күчерү буенча республика адреслы программасына (алга таба – Программа) кертелгән күпфатирлы йортлар булу.

6. Муниципаль берәмлек бюджетына субсидия күләме Программаның шартлары нигезендә, муниципаль берәмлектәге гражданнарны күчерү ысулын исәпкә алып, түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$ОТМО_i = Ц_i \times кв.м_iМС_n \times Y_i ,$$

монда:

i – муниципаль берәмлек исеме;

ОТМОi – i муниципаль берәмлегенә субсидия күләме;

$Ц_i$ – гражданнарга бирелә торган торак урыннарның бер квадрат метр гомуми мәйданының планлаштырыла торган кыйммәте күләме яки i муниципаль берәмлегендә Программага кертелгән авария хәлендәге күпфатирлы йортларда гражданнар милкендәге алына торган торак урыннарның бер квадрат метр гомуми мәйданы өчен планлаштырыла торган сатып алу бәясе күләме (күченү ысулына карап);

$кв.м_iМС_n$ – i муниципаль берәмлегендә таратып урнаштырылырга тиешле авария хәлендәге торак фондының квадрат метры саны;

$Y_i$ – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан ел саен раслана торган һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Җирле бюджетларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр формалаштыру, бирү һәм бүлү кагыйдәләрен раслау турында» 2019 ел, 20 сентябрь, 851 нче карары белән расланган Җирле бюджетларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр формалаштыру, бирү һәм бүлү кагыйдәләренең (алга таба – Субсидияләрне формалаштыру, бирү һәм бүлү кагыйдәләре) 13 пункты нигезендә билгеләнә торган Татарстан Республикасы бюджетыннан муниципаль берәмлекнең чыгым йөкләмәләрен финанслашуның иң чик дәрәҗәсе.

7. Муниципаль берәмлекләр бюджетлары арасында субсидияләр бүленеше тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы белән раслана.

6. Субсидияләр бирү шартлары:

гражданнарны авария хәлендәге торак фондыннан күчерү буенча расланган муниципаль адреслы программа булу;

муниципаль берәмлек бюджетында (муниципаль берәмлек бюджетының җыелма бюджет исемлегендә) финанслашу максатларында субсидия бирелә торган муниципаль берәмлекнең чыгым йөкләмәләрен үтәү өчен бюджет ассигнованиеләре аларны үтәү өчен җитәрлек күләмдә (Татарстан Республикасы бюджетыннан бирергә планлаштырыла торган субсидия күләмен кертеп) булу;

Министрлык һәм муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органы арасында муниципаль берәмлекнең финанслашу максатларында субсидия бирелә торган чыгым йөкләмәләрен үтәү йөкләмәсен күздә тота торган килешү (алга таба – Килешү) төзү һәм Килешүдә каралган йөкләмәләрне үтәмәгән өчен җавап бирү.

9. Субсидияләр алу өчен муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органнары

Министрлыкка түбәндәге документларны тапшыра:

ирекле формада язылган субсидияләр бирүгә заявка;

җирле үзидарәнең вәкиллекле органы карарыннан вәкаләтле зат тарафыннан таныкланган һәм муниципаль берәмлек бюджетында Программаны гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итү буенча муниципаль берәмлекнең чыгым йөкләмәләрен үтәү өчен бюджет ассигнованиеләре булуын раслый торган агымдагы финанс елына муниципаль берәмлек бюджеты (җыелма бюджет исемлеге) турында өземтә;

авария хәлендәге торак фондыннан гражданнарны күчерү буенча муниципаль адреслы программаның билгеләнгән тәртиптә таныкланган күчермәсе.

10. Субсидия Министрлык һәм муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органы арасында Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан расланган бертип форма буенча Субсидияләр формалаштыру, бирү һәм бүлү кагыйдәләренең 10 пунктына таянып төзелә торган Килешү нигезендә бирелә.

11. Татарстан Республикасы бюджетыннан муниципаль берәмлек бюджетларына субсидия акчасын күчерү Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча территориаль органнарында муниципаль берәмлекләрнең финанс органнарына ачылган муниципаль берәмлекләр бюджетларының бердәм счетына гамәлгә ашырыла.

12. Муниципаль берәмлекләр тарафыннан субсидияләрдән файдалану нәтиҗәлелеген бәяләү Министрлык тарафыннан субсидиядән файдалану нәтиҗәлелегенең Килешүдә билгеләнгән һәм факттагы ирешелгән күрсәткече белән чагыштыру нигезендә гамәлгә ашырыла.

13. Муниципаль берәмлектәге җирле үзидарәнең вәкаләтле органы Министрлыкка Килешүдә билгеләнгән формада, срокларда һәм тәртиптә муниципаль берәмлекләр бюджетларының финанс белән тәэмин итү чыганагы булып субсидия торган чыгымнары һәм Программада каралган субсидиядән файдалану нәтиҗәлелегенең (нәтиҗәсенең) планлаштырыла торган күрсәткечләрен үтәү турында хисаплар тапшыра.

14. Муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары һәм аларның вазифаи затлары тапшырыла торган хисап мәгълүматының дөрес булмавы һәм субсидияләрнең максатчан файдаланылмавы өчен законнар нигезендә җавап бирә.

15. Килешүдә каралган йөкләмәләр бозылган очракта, муниципаль берәмлекләр бюджетларыннан Татарстан Республикасы бюджетына акчаны кире кайтару һәм аларны алга таба файдалану тәртибе һәм шартлары Субсидияләрне формалаштыру, бирү һәм бүлү кагыйдәләренең 15 – 18, 23 пунктларында билгеләнде.

16. Муниципаль берәмлек тарафыннан субсидия бирү шартлары бозылган очракта, аңа карата Россия Федерациясе бюджет законнарында каралган мәҗбүр итүнең бюджет чаралары кулланыла.

17. Субсидиядән максатчан файдаланылмау Татарстан Республикасы бюджетыннан алынган акча суммасын законнар белән билгеләнгән тәртиптә бәхәссез түләтүгә китерә.

18. Агымдагы финанс елының 1 гыйнвары хәленә карата субсидияләрнең файдаланылмый калган өлеше, Килешүдә каралган очракларда, агымдагы финанс елы-

ның беренче 15 эш көне эчендә Татарстан Республикасы бюджеты керемenә кире кайтарылырга тиеш.

19. Субсидияләрнең файдаланылмый калган өлеше Татарстан Республикасы бюджеты керемenә күчерелмәгән очракта, әлеге акча Татарстан Республикасы бюджеты керемenә, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән гомуми таләпләрне үтәп, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнә торган тәртиптә түләтелергә тиеш.

20. Субсидияләрдән максатчан файдалануны контрольдә тоту Министрлык һәм дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан законнар нигезендә гамәлгә ашырыла.